Республика Татарстан
Совет Новоимянского сельского
поселения Сармановского
муниципального района
ул. Гагарина, д. 39, с.Кутемели, 423355.
Телефон: (85559) 4-63-36, факс: 4-63-36

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге Советы
Гагарин урамы, 39 йорт, Күтәмәле авылы,
423355. Телефон: (85559) 4-63-36, факс: 4-63-36

ОКПО 93068373 ОГРН 1031604000174 ИНН/КПП 1636001308/163601001

**12.10.2018** **№3**

**КАРАР**

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
«Яңа Имән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
генераль план проекты буенча
гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Яңа Имән авыл җирлеге уставы, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. 2018 елның 12 ноябрендә 14 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Яңа Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар: Сарман районы, Күтәмәле авылы, Гагарин урамы, 39 йорт адресы буенча узачак.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен комиссия түбәндәге составта төзергә:

Гәрәев Р.Ф. - Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Арсланова Н.А.. - Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге рәисе урынбасары (3 нче округ);

Сабирова А.А. - Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге депутаты (1 нче округ).

3. 2018 елның 12 октябреннән 12 ноябренә кадәр чорда «Яңа Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты материаллары экспозициясен Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге

башкарма комитеты бинасында оештырырга: Сарман районы, Күтәмәле авылы, Гагарин урамы, 39 йорт.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 423355, Татарстан Республикасы: Сарман районы, Күтәмәле авылы, Гагарин урамы, 39 йорт (Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Имән авыл җирлеге
Башлыгы Р.Ф.Гәрәев